**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Илбәк авыл җирлеге Советы карары**

Илбәк авылы № 82 2018 ел, 10 апрель

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 2017 елның 04 сентябрендәге 57 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларына белешмәләр бирү «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру тәртибенә үзгәреш кертү турында

2012 елның 03 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон нигезендә

Илбәк авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 2017 елның 04 сентябрендәге 57 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларына белешмәләр бирү «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру тәртибенә үзгәреш кертеп 3 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«г) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган (килешү эшләнгән) акчалар алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч ел эчендә муниципаль вазыйфаны биләүче затның гомуми кеременнән артып китсә. "

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Рәис Л.Р.Әсәдуллина